ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Большие Меми

22.07.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 17

«2024 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварыннан 5 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Олы Меми авыл җирлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының «Югары Ослан муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 2024 елның 26 апрелендәге 44-600 номерлы карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1.«2024 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварыннан 5 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 22 июленнән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина